СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*6 ноябрь, 1998 ел.*
*ҖОМГА*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 127 (8284)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

## БҮГЕН - ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ КӨНЕ

**7 НОЯБРЬ - БӨЕК ОКТЯБРЬ СОЦИАЛИСТИК РЕВОЛЮЦИЯСЕ БУЛГАН КӨН - ТАТУЛЫК ҺӘМ КИЛЕШҮ КӨНЕ.**

*Кулдан - кулга*

### Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН:

# «ЗАМАНАЛАР НИЧЕК КЕНӘ ҮЗГӘРМӘСЕН, БАРЫБЕР ЭШЛӘМИЧӘ БУЛМЫЙ»



***- Фатих Сәүбәнович, ике зур бәйрәм, ике зур сәяси дата якынлаша - 6 ноябрь - Татарстан Республикасы Конституциясе көне һәм 7 ноябрь - Октябрь революциясе булган көн һәм анысы икенче ел инде татулык һәм килешү көне дип билгеләп үтелә. Быел шулар алдыннан гына ТР Дәүләт Советының уналтынчы пленар сессиясе булып үтте, анда көн тәртибендәге төп мәсьәләләр белән беррәттән иң актуаль агымдагы проблемалар да күтәрелде. Шәхсән үзегезнең тәэсирләрегез белән уртаклашсагызчы.***

- Кызганычка каршы, сүзне барыбызга да мәгълүм фактны тәкърарлаудан башларга туры килә: илдә - кризис, һәм ул безнең республиканы, безнең районны да читләтеп үтә алмый. Бюджетны, аның керем өлешен формалаштыруда шактый ук зур әһәмияткә ия булган әйдәп баручы машина төзелеше, нефть, нефть химиясе тармакларында ул аерата кискен һәм авыр чагылды.

Үзегез беләсез, бездә дә, республикада да Зүзәй нефть эшкәртү заводын сафка кертү, аның базасында яңа нефть һәм газ чыгару идарәсе оештыруга билгеле бер өмет багланган иде. Әмма... Әлегә "Татнефтепром"-ның яңа производствога финанс салырга димим, хәтта үз исәп - хисап счетын бирергә дә мөмкинлеге юк. Ә бу теләсә кайсы инициативаны, теләсә нинди мөстәкыйльлекне тышаулый.

Бюджетка кагылгач, икенче бер мәсьәләне дә әйтим инде. Агымдагы елда район иске акча белән 13,5 миллиард сумны республика казнасына һәм бюджеттан тыш фондларга бирде. Ә бит без бу средстволар исәбенә хезмәт хакы һәм пенсия түләүләрдән башлап яңа эш урыннары төзүгә кадәр күп җитештерү һәм социаль проблемаларыбызны хәл итә алган булыр идек.

Быелгы корылыкның безнең тез астына ничек каты сукканлыгын да әйтми үтә алмыйм. Тик, иген уңмауга да карамастан, товар кредитларын кайтарырга кирәк, димәк, юл бер генә - эшләргә дә эшләргә, азрак чыгымнар белән күбрәк товар продукциясе җитештерергә.

***- Фатих Сәүбәнович, бүген җәмгыятьтә төрле дәрәҗәләрдә бер нәрсә турында сөйлиләр: янәсе, реформаларга чик куела, элеккеге команда - административ системага кире кайтылачак. Бу шулаймы?***

- Мин бу процессны бөтәнчә атар идем. Икътисадый өлкәдә тәртип булдыруның күптән өлгереп җиткән зарурлыгы ул. Хәзерге этапта ул дәүләт тарафыннан көйләүнең ролен көчәйтүне күздә тота, әмма тупланган базар тәҗрибәсеннән баш тарту турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Ил, республика җитәкчеләренең позициясе дә шундый. Хакимият башлыклары, республика министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре белән Казанда үткәрелгән соңгы киңәшмәдә Минтимер Шәрипович Шәймиев ориентирларны ачык билгеләде: икътисадта күпукладлылык, милекнең төрле формалары сакланачак.

Сүз дә юк, кайсы акционерлык җәмгыятенең ничек эшләвен ачыкларга вакыт җиткәнлеге башка нәрсә. Һәр адымда һәм һәркайда акционерларның җитештерүне үстерүгә бернинди дә өлеш кертмәүләре күзәтелә. Ә бит предприятие акционерлаштырылган икән, милек ияләре инвестиция кертергә тиешләр. Бу - беренче шарт, икенчесе - хуҗалар җитештерүне үстерүне тәэмин итәргә тиеш. Безнең районда акционерлашкан 12 предприятие исәпләнә, алар арасында Нурлат шикәр заводы, ит комбинаты, сөт - май комбинаты, элеватор, "Агрохимсервис" һәм башкалар бар. Кызганычка каршы, бүгенге көндә ул предприятиеләрнең берсе дә табыш алуны тәэмин итә алмый, акционерларга дивидендлар да түләнми. Шуңа күрә, акционерлашкан һәр предприятиенең җитәкчесе дә ел ахырына кадәр зыянсыз эшләүгә күчүне күздә тоткан үсеш программалы бизнес - план тәкъдим итәргә тиеш. Җитәкчеләрнең потенциаль мөмкинлекләре турында объектив бәяләмәләрдән чыгып нәтиҗә ясаячакбыз.

Авылга килгәндә, монда кабул ителгән 7 юнәлеш буенча реформалаштыру дәвам итәчәк, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә тагын да җитдирәк игътибар бирәчәкбез. Ике ел эчендә без эшлексезлек инерциясен җиңә, тормышның барлык өлкәләрендә, кешеләрнең аңында җитди алга китешләргә ирешә алдык. Боларны ныгытырга һәм тагын да үстерергә кирәк. Хәзерге кризис шартларында үз товар җитештерүчеләребезгә ихтыяҗның булуы моңа зур стимул бирә.

***- Фатих Сәүбәнович, районны үстерүнең Сез гамәлгә ашыра торган программасы авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү предприятиеләренә карата да җитди адымнарны күздә тота.***

- Әйе, хәзер үз эшкәртү тармагыбызны үстерүгә җитди игътибар бирү бик вакытлы - читтән кертелгән товар белән генә халыкны туендырып булмаячак, аннары азык - төлек импорты кискен кимеде дә, алга таба тагын да начаррак буласы. Шуңа да без беренче чираттагы бурычлар рәтенә ит комбинатын бирегә ахыр чиктә 53 төрдә продукция, аны да нигездә "Нурлат" агрофирмасында җитештерелгән иттән эшләп чыгарырга мөмкинлек бирерлек итеп реконструкцияләүне төгәлләүне кертәбез. Бу ахыр продукциянең бәясен бераз арзанайтырга мөмкинлек бирәчәк, димәк, аны халык та сатып ала алачак. Ул продукцияне тышкы базарда да конкуренциягә сәләтле итәргә кирәк. Аннары НГДУ каршындагы тегермәнне киңәйтеп, шунда ук пекарня ачу нияте дә бар. Киләсе елдан башлап нефть һәм газ чыгару идарәсенең май сыгу цехын үз чималыбыз белән тәэмин итә башлаячакбыз, ягъни күпмедер мәйданда көнбагыш игеләчәк. Авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алу, аны эшкәртү һәм реализацияләүдә кулланучылар кооперациясе системасына җитди өмет баглыйбыз. Моның өчен беренче чиратта хәзерләүләр конторасының эш стилен радикаль үзгәртергә, шулай ук азык комбинатындагы технологик җиһазларны заманчалаштыру эшен дәвам иттерергә кирәк. Аерым алганда, бирегә төрле эчемлекләрне шешәгә тутыру буенча заманча линия урнаштырырга планлаштырабыз. Төрнәс спирт заводында ректификат спирт чыга башлау алдында, ә 1999 елдан үз спиртыбыздан аракы эшли башлау планлаштырыла. Моның безнең өчен өч зур өстенлеге булачак: беренчедән, безнең хуҗалыкларның арышын түмәрләп сатып алучы, икенчедән, малларга кыйммәтле азык - барда була, өченчедән, предприятие район бюджетына салымнарны тулы күләмендә түли алачак.

(Ахыры 2нче биттә).

## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ ПЛЕНАР СЕССИЯСЕ

30 октябрьдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 16нчы пленар сессиясе булды.

Сессия кабат караганнан соң "Татарстан Республикасының Конституцион суды турында"гы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында"гы Законны кабул итте. "Татарстан Республикасы гражданлыгы турында"гы һәм "Татарстан Республикасының бюджеттан тыш дәүләт фондлары турында"гы закон проектлары икенче укылышта кабул ителде. Сессия "Дәүләт хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында"гы закон проектын кире какты. "Җир өчен түләү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында"гы закон проекты беренче укылышта кабул ителде. "Татарстан Республикасы Конституциясенең 89,111нче маддәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" һәм "Иминлек турында"гы закон проектлары беренче укылышта кабул ителде.

"Татарстан Республикасы алдында аерым хезмәтләре булган гражданнарны өстәмә матди тәэмин итү турында" закон проекты беренче укылышта кабул ителде. "1998 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында"гы закон проекты тулаем кабул ителде.

Сессиядә башка мәсьәләләр дә каралды.

## СҮЗ - САЛЫМНАР ТУРЫНДА

***Узган атнада Казанда Россия салым инспекциясе башлыгы Георгий БООС җитәкчелегендә делегация булып китте.***

Мәскәү делегациясен Кремльдә Президент Минтимер Шәймиев кабул итте. Кунакларны котлау сүзендә республика башлыгы РФ салым хезмәтенең яңа җитәкчесенең эшне ничек башлавы күңеленә хуш килүен әйтте. "Бүген бары тик бюджетны салым исәбенә тулыландыру гына кризистан чыгу өчен нигез булачак",- диде ул. Бюджетара мөнәсәбәтләргә тукталып, Президент Үзәктән бер тиен дә алмыйча, берничә федераль объект төзелүен, халыкның аз керемле катлавына ярдәм итәргә тырышуын искәртеп үтте. Шул уңайдан, Россия Финанс министрлыгы бюджетара килешүне бозды. Бу гамәл Шартнамәне бозарга маташу да. Моның нәтиҗәләре бик җитди булырга мөмкин. Әгәр дә хәл ел ахырына кадәр үзгәрмәсә, Шартнамә буенча Татарстан бюджетын үзе башкарачак. Киләсе елга бюджетны кабул иткәндә дә без шуннан чыгып эш итәчәкбез. Шунысын да искәртик, Татарстан үзе бернинди килешүләрне дә бозмады һәм бозарга җыенмый да. Үзара исәп - хисапларга килгәндә исә, Федераль үзәк Татарстанга үзе бурычлы, диде.

**("Татар - Информ").**

*Редакциядә телефон шалтырады*

## БЕР ПРОБЛЕМА ХӘЛ ИТЕЛДЕ

"Сельхозтехника" микрорайонындагы йортларның тиешенчә, ә күп вакыт бөтенләй җылытылмавы анда яшәүчеләр проблемасына гына түгел, ә кайбер башка предприятиеләр һәм инстанцияләр бәласына да әйләнгән иде. Безнең газета да шул ук мәсьәләне кат - кат күтәреп чыкты. Һәм бүген, ниһаять, укучыларыбызга проблеманың уңай хәл ителүе турында хәбәр итәсебез килә: торак йортларның барысы да диярлек машина төзү заводындагы газ белән ягыла торган котельняга тоташтырылды. (Калган эшләр дә төгәлләнеп килә.) Безгә бу хакта шунда яшәүче Л.Н.Коростелева шалтыратты һәм шул бистә халкы исеменнән проблеманы аңлап, олы ярдәм күрсәтүчеләргә рәхмәтен белдерде. Халыкка кышны җылы өйләрдә каршы алырга мөмкинлек тудыручы - иң беренче чиратта, шәһәр һәм район җитәкчелеге һәм шуңа рәхмәтнең дә иң зурысы алар исеменә. Шулай ук алар җылылык челтәре предприятиеләре җитәкчелегенә һәм бигрәк тә барлык эшләрне турыдан - туры гамәлгә ашыручы котельня мастеры Х.Г. Таһировка, торак - коммуналь хуҗалыгы идарәсе һәм "Сельхозтехника" АҖ җитәкчелегенә зур рәхмәтләрен белдерәләр.

## Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН:

# «ЗАМАНАЛАР НИЧЕК КЕНӘ ҮЗГӘРМӘСЕН, БАРЫБЕР ЭШЛӘМИЧӘ БУЛМЫЙ»

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә).**

Һәр подразделение һәм структураның азык - төлек продуктлары белән үзен үзе тәэмин итүе мәсьәләсе беренче планга чыга. Һәм монда безнең файдаланылмаган күп резервларыбыз бар. Мәктәп коллективларын гына алыйк. Аларның үз ашханәләрен барлык төр яшелчә, бәрәңге белән, бу эшне башкалар җилкәсенә салмыйча, тулысынча үзләре тәэмин итәргә хәлләреннән килә. Шуңа да киләсе елдан мәктәпләргә җир участоклары бүлеп бирәчәкбез, ә мөмкин булган урыннарда балалар терлек, кош, куян үрчетү белән шөгыльләнәчәк. Бу бердән хезмәт тәрбиясе дә булачак, укучы яшьләрнең әлегә мәгънәсезгә уза торган буш вакытын да тутырачак, югыйсә соңгысы балаларның көнкүрештә дә, җәмәгать урыннарында да тискәре гамәлләренә китерә бит.

*- Фатих Сәүбәнович, бу әңгәмәдә социаль проблематика турында һич тә дәшми калу мөмкин түгел...*

- Килеп туган кискен шартларда, кызганычка каршы, халыкның аерым категорияләрен социаль яклауны кысу турында сүз алып барырга туры килә. Икенче төрле әйткәндә, социаль яклау катгый төстә адреслы гына булырга, иң мохтаҗларга гына күрсәтелергә тиеш. Пенсионерларга социаль хезмәт күрсәтү буенча территориаль үзәк төзү бурычы тора, ул бер үк вакытта үзенә күрә реабилитация үзәге дә булып китәргә мөмкин. Өлкәннәргә теләсә нинди түләүле хезмәтләр дә шул үзәк аша күрсәтеләчәк. Халыкның юксыл катламнарын яклауның азык - төлек җыелмалары бирү формасы гамәлгә ашырылачак. Шул максатлардан без юридик һәм физик затларның ирекле иганәләрен дә эзләячәкбез. Халыкка шундый авыр булган заманнарда без читтә кала алмыйбыз.

*- Районның барлык халкына булышуның иң нәтиҗәле формасы - ул, берсүзсез, газлаштыруны тизрәк төгәлләү. Бу яктан, Фатих Сәүбәнович, без кешеләрнең шәхсән сезгә бик зур өметләр баглавын беләбез.*

- Әйе, газлаштыру буенча бик зур эш башкарылды дип, горурланып та, җиңелрәк сулап та әйтә алам. Бу ике елда республиканың башка районнары белән чагыштырып та булмаслык гаять зур сикереш ясалды. Хәзерге шартларда зур җиңү дип саныйм мин моны. Табигый газ гамәлдә һәр торак пунктка барып җитте инде, тик газлаштыруны төгәлләү күп яктан халыкның үзеннән, кешеләрнең акча табуыннан тора. Асылда һәр хуҗа газчыларга түләргә кирәк булган кадәр сумманы утын, күмер, брикет алуга тота бит. Бер тапкыр газчыларга түләп, ягулык мәшәкатеннән бөтенләйгә котылу яхшырактыр инде. Әле алар белән итләтә, терлекләтә исәп - хисап ясарга да мөмкин - монысы авыл өчен кулай вариант дип саныйм. Тик акча җыюны сузмагыз, соңрак тагын да кыйммәтләнәчәк дип кенә кисәтәсем килә. Алга таба газсыз ничек яшисең ди? Әмма дәүләт акчасы исәбенә рәхәткә чыгу заманнары узды, үз средстволарыңа карап яши башларга вакыт. Ничек эшләсәк, шулай яшәрбез. Гадәти көннәребезгә дә, бәйрәмнәребезгә дә кагыла бу.

*- Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Фатих Сәүбәнович. Сезнең үзегезгә дә нурлатлылар хакына яңадан - яңа башлангычларыгызда уңышлар һәм яхшылык кына телибез.*

**Әңгәмәдәш - Д.ТӘМАЕВА.**

# АВТОМОБИЛЬЛЕЛӘР КОЛАГЫНА

***Сишәмбе көнне, 3 ноябрьдә "Нурлат машина төзү заводы" акционерлык җәмгыятендә техник хезмәт күрсәтү станциясен ачу булды.***

***Вакыйга үзе Нурлат өчен гадәттән тышлардан һәм игътибарга лаек булса да, тантанага чакырулылар күп түгел иде. Дөрес, станцияне бар шартын китереп - ал тасма кисеп ачтылар, хуҗалар һәм кунаклар чыгыш ясады, вакыйганы видеокамерага да төшерделәр.***





Тәкъдир итүне башлап җибәргәндә АҖ генераль директоры Ю.М. Жемков бүгенге икътисадый кризис кочагында шәһәрдә һәм районда 1 - 2 генә яңа эш урыны булдыру да вакыйгага әверелә, ә инде 15 - 20 урын табылу аерым игътибарга лаек дип билгеләп үтте. Моның белән килешмичә булмый. Цехлар, участоклар, тулы бер предприятиеләр ябылып, кешеләр язмыш кочагында калган бер вакытта биредәге коллектив заводның бер цехы базасында ике ай дигәндә техник хезмәт күрсәтү пункты ачып, автомобильләргә диагностика һәм техник карау кебек хезмәтләр комплексы тәкъдим итә. Әлегә җиңел машиналарга гына, әмма алга таба йөк машиналары да кабул ителәсе. Генераль директорның фикерен ЮХИДИ начальнигы Х.В. Әюпов та хуплады, ул районда хәзер 5 мең җиңел машина исәптә торуын, тугыз айда гына да 900 берәмлек учетка куелуын, моннан тыш 3 мең йөк машинасы да булып, Нурлатта диагностика станцияләре санаулы гына икәнлеген әйтеп, шуңа күрә бу станция автомобильчеләргә сайлау мөмкинлеге бирәчәк, диде: монда руль идарәсен дә, тормозларның көйләнешен дә тикшерәләр, эшкәртелгән газларда углерод окисеның микъдарын да билгелиләр. Мондый цехның ачылуы максатка ярашлы булуын хакимият башлыгы урынбасары - дәүләт һәм коммуналь милек белән идарә итү комитеты рәисе Ю.А. Муракаев та таныды. СТОның үз клиентларын табачагына ышаныч белдереп, ул коллективка координацияле, максималь файда алырлык итеп эшләүләрен теләде, ә соңгысы җирле бюджетка да саллы өлеш кертер.

Яңалыкны генераль директорның урынбасары М.Ю.Жемков һәм мастер В.Н.Евсеев күтәреп чыкканнар икән. Идея шәһәр һәм район җитәкчелегендә хуплау тапкан. Мөмкинлекләр һәм ихтыяҗ ачыкланган, икътисадый исәпләүләр ясалган. Инициаторларның беренчесе фирма эшләре буенча Мәскәүгә чыгып киткән иде, аның каравы икенчесе килүчеләрне кызыксындырган сорауларга бик теләп җавап бирде, коллектив белән таныштырды. Җидесе дә тәҗрибәле егетләр, тантанада барысы да махсус билгеләр төшерелгән "фирменный" киемнәрдән иде. СТО тиңдәш станцияләрдәге кебек үк хезмәтләр күрсәтә: шиннар монтажлау, май алыштыру, фараларны, автотестер ярдәмендә двигательне, тәгәрмәчләрнең юнәлешен һәм аралыгын көйләү... Соңгысын шәхси мастерскойда гына башкару мөмкин түгел. Кыскасы, станция коллективына эш бетеп тормас. Һәр эшне сыйфатлы итеп, профессиональларча һәм гарантия белән башкарачакларына ышандыралар. Цех әлегә 300 квадрат метр мәйдан били, һәм киләчәктә аны киңәйтергә ниятлиләр. Цехта чиста, идәнгә плитәләр җәелгән, юу, күтәрү җайланмалары бар, ә бору түгәрәген һәм тагын кайбер җиһазларны бригада үзе монтажлаган. Буфет, автозапчастьлар кибете өчен дә урын булачак, ә капка төбендә автомашиналарны куяр өчен саклаулы урын бар.

Станция кайчан эшли башлаячак соң? Иртәгә үк керешә алабыз, диделәр. Шулай булгач, машинасы булганнар безнең әйткәннәрне колакларына әләрләр дип уйлыйбыз.

**Т.НАЗАРОВА.**
**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

# ТАРИХ АЛГА ӨНДИ

Барыбыз да белгәнебезчә, тиздән Октябрь революциясе бәйрәме җитә. Шушы юбилейга һәм хәзерге чорга карата, мин, тарихчы буларак, үземнең фикеремне язасым килә. Чөнки, нәрсә генә булмасын, безнең ил, халкыбыз 1917нче елдагы кебек үзенә тагын юл сайлый. Иске юлга кайтыргамы, әллә барлык алга киткән илләр сайлаган хокукый дәүләт төзергәме? Күп халык хәзер авырлыкларның чын мәгънәсен аңламыйча үткәннәргә бәя бирә.

Әйе, 1991нче елдан алып хәзерге вакытка кадәр күп газета битләрендә, радио, телевидение тапшыруларында Советлар Союзы тарихы тискәре яктан гына күрсәтелде. Гади кеше, мәктәп баласы аларны укып, ишетеп нинди нәтиҗәгә килә ала соң? Минемчә, күп очракта шундый фикергә килергә була: Октябрь революциясенә кадәр рус империясендә халык бик әйбәт яшәгән булган, ләкин Ленин җитәкчелегендәге большевиклар ул "җәннәт"не бетергәннәр. Әмма карагыз әле, мәктәп дәреслеген ачып булса да! Октябрь революциясенә кадәр бит февраль революциясе булган. Власть буржуазия кулына күчкән. Ник соң ул буржуазия илдә тәртип урнаштыра алмаган? Ә җавабы аның бик гади - рус империясендә ул буржуазия әле властьны үз кулына алырга әзер булмаган. Монда тагын бөтендөнья сугышын да искә алсак, гади халыкның ник большевикларны сайлаганын аңлау бик үк авыр түгел. Чөнки большевиклар, хәзерге партияләрнең күбесе кебек үк, нәрсә вәгъдә бирергә була, барысын да вәгъдә иткәннәр. "Җәннәт"тә яшәсә, халык, әлбәттә, бу юлны сайламаган да булыр иде. Ә бернинди хокукы булмаган төрле милләт халыкларына башка юл булдымы икән соң?

Шулай булгач, Октябрь революциясе нишләп большевикларның гына перевороты булсын ди. Ул гасырлар буе изелгән халыкның мәҗбүри сайлаган юлы булып чыга түгелме соң? Бөтендөнья тарихында аның әһәмиятен Бөек француз революциясе белән чагыштырырга була. Шуның берсен генә алыйк. Безнең революциянең илдә нинди нәтиҗәләр китереп чыгарганын барыбыз да беләбез. Күп дәүләтләр, бездәге хәлләрне күреп, халыкларны изү юлын ташлап, аларга хокуклар бирү юлын сайлаганнар. Шуңа күрә дә алар хәзер "чәчәк ата" торган дәүләтләр санала. Ә безнең илдә халык бер коллыктан икенче коллыкка гына килеп эләккән. Революция һәм аннан соңгы вакыйгалардан соң ул шул дәүләт колына әйләнгән. Кеше ул дәүләт өчен үләргә әзер торса да, яраткан дәүләте аңарга кеше хокукларын бирергә ашыкмаган. Ул, беләсезме, нәрсәдән курыккан? Ул хокукларны халыкка бирсә, коммунистларга властьны үз кулларында саклап калу авыр була икән, ләбаса. Аннары бит коммунист түрәләргә дә чын "коммунистлар" кебек эшләргә туры килер иде. Анда инде халыкның ышанычын саклап калу бик икеле.

Минемчә, Октябрь революциясен дә, Советлар Союзының тарихын да өйрәнеп дөрес бәя бирү киләчәктә генә мөмкин булачак. Ә хәзер безнең сәясәтчеләребез аны халыкка, үзләренә ничек кирәк, шулай аңлаталар. Миңа калса, Советлар Союзы тарихын мин рус империясенең хокукый дәүләт төзү юлында беренче адымы, беренче баскычы дип алыр идем.

Безнең халыкларның (ул татармы, русмы, чувашмы) үзенең бөек тарихы һәм киләчәге бар, ләбаса. Менә "Дуслык" газетасының бер санында Зирекле авылының, чуваш милләтеннән булган авыл белән кушылгач, канәгать булмавы турында бер язма укырга туры килде. Юк, минемчә, хәзерге вакытта андый нәрсәләр күтәрү ул бик зур хата. Шул ук чувашлар белән без бер мең елдан артык яшибез бит инде. Гади генә сүзлекне алып карасак та, анда чувашларның төрки халыклар төркеменә кергәнен күрергә мөмкин бит. Явыз Иван эшләгән эшләр өчен хәзерге урыс халкының нинди гаебе бар? Казан ханлыгы басып алынуда татарларның үзләренең гаебе ни дәрәҗәдә? Сораулар бик күп. Ул сорауларга без "салкын" баш белән, бар яктан да өйрәнеп җавап бирергә тиешбез.

Безгә революцияләр, талаулар кирәк түгел. Үзебезгә үзебез хуҗа булырга, коллыктан котылырга, сайлауларда безне яклый ала торган кешеләрне сайларга кирәктер, бәлки. Үзеңә хуҗа булу - ул бик зур җаваплылык. Бу җаваплылыктан качарга кирәк түгелдер безгә, бәлки.

Минемчә, тарих ул безне артка тәгәрәргә түгел, барлык үткән кимчелекләрне өйрәнеп алга барырга өнди.

**И.ТИМЕРБУЛАТОВ,**
**Яңа Иглай урта мәктәбенең тарих укытучысы, туган якны өйрәнү музее җитәкчесе.**

# КҮҢЕЛ КӨР, ҖАН САУ БУЛГАЧ



Фотохәбәрчебез **Н.АЗИЗОВ** төшергән бу сурәткә бер елдан артык инде. Тик рәсемдәгеләрнең, инде пенсиядә булсалар да, әле һаман әнә шулай көр күңел белән, туган авылларының хуҗалык тормышын элеккечә үк якын күреп, бүгенге яшьләргә кулларыннан килгәнчә ярдәм итеп йөргән көннәре икән. Анысын шушы арада гына редакциягә кереп чыккан хәбәрчебез, хәзер "Татарстан" хуҗалыгы белән берләштерелгән "Әлмәт"тә баш икътисадчы да булып эшләгән, кирәге чыккач агроном вазифаларын да һич авырсынмыйча башкарган Җәүдәт ага Хәйруллиннан сорап белештек. Былтыр да, өч пенсионерның техника паркында бергә туры килүеннән файдаланып, үзләрен рәсемгә төшереп алырга ул киңәш итте. Китапча әйтсәк, өчесе дә күптән лаеклы ялда, өйдә генә утырсалар да, берсенә бер сүз әйтүче булмас иде. Әмма бокай да тынгысыз җаннар алар, аннан, хуҗалыкның аларга эше төшми дә тормый. Эш төшү дигәннән, тимерче булып эшләгән Әсгать ага Сабитовның (рәсемдә сулда), пенсия яшенә җиттем дип алачыктан китеп торганы да булмады бугай әле. Сүз уңаеннан, уллары Әхәт белән Әфгать тә туган авылларында, эшнең ниндиен кушсалар шунысын карышмыйча башкаралар. Гомер буе трактор йөрткән Габделәхәт ага Хөснетдиновка да (уртада) гел эш чыгып тора авылда. Әле менә быел да яз буе чәчүдә булды, печән һәм урак өстендә елдагыча тракторына эскерт өйгеч беркетте, кышка керсә, шул үзе эскертләгән салам - печәннәрне төяп фермага озатып тору да аның вазифасына керә. Бу фото да Габделәхәт аганың кырдан кайтып кына туктаган тракторы янында төшереп алынган иде бит. Ә ул көнне иртәрәк кайтуының сәбәбе эскерт өйгечнең кай төшендер эретеп ябыштыру кирәклегеннән иде. Анысын ул чакта кордашы Вәлимәрдән ага Нигъмәтуллин (уңда) күз ачып йомганчы менә дигән иттереп ябыштырып бирде. Күп еллар буе колхозда шул хезмәттә булган Вәлимәрдән ага эшне аннан - моннан гына башкара белми дә инде анысы. Заманында аның ничек эшләвен күреп сокланып, газетада "Вәлимәрдән чаткылары" дигән язма да биргән идем. Инде пенсиягә чыкканына да берничә ел икән Вәлимәрдән аганың. Әмма гозерләп килгәндә техника паркына да, улы Рәис эшләп йөри торган фермага да барып ашыгыч эшләрне башкарып кайтырга иренми, диде Җәүдәт ага ветераннарның өчесе турында да әнә шулай бик якын итеп. Ә Җәүдәт аганың сүзе аның үз шәхси фикере генә түгел ул, идарә аппаратында эшләгән, пенсиядә булуына карамастан, әле быел да җаваплы вазифа башкарган кеше буларак, хуҗалык җитәкчелегенең дә фикере.

**Р.МУЛЛИН**

МӘГАРИФ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

# ЧУВАШ ТЕЛЕ УКЫТУЧЫЛАРЫ СЕМИНАРЫ

30 октябрьдә Аксумла урта мәктәбендә районның башлангыч һәм урта мәктәпләрендә чуваш теле укытучыларының семинары булып үтте. Семинар эшендә район мәгариф бүлеге методисты О.С.Тарасова, мәгълүмат - прокат үзәге (фильмотека) хезмәткәрләре катнашты.

Ольга Семеновна Тарасова семинарда катнашучыларны 1998-99 уку елына бурычлар белән таныштырды, ул шулай ук чуваш телен беренче генә ел укытучыларның квалификациясен күтәрүгә кагылышлы кайбер мәсьәләләргә дә тукталды.

Семинарда катнашучылар Аксумла мәктәбенең чуваш теле һәм әдәбияты укытучысы Г.М.Ендиряковның "Чуваш телендә архаизмнар һәм неологизмнар" дигән темага ачык дәресендә булдылар. Дәресне тикшерү барышында кунаклар Геннадий Михайловичның аны югары методик дәрәҗәдә, таблицалар һәм башка күрсәтмәлекләр кулланып уздыруын билгеләп үттеләр.

Класстан тыш чара да кызыклы булды. Укучылар анда РФ Язучылар берлеге әгъзасы Ф.А.Савгачевның пьесасыннан бер өзек уйнап күрсәттеләр. Сәхнәләштерүдә төрле сыйныф укучылары катнашкан: Алена Акмуллина һәм Люба Улаева - 11 нчедән, Женя Туймешев - 9 нчы, Валера Ендиряков - 5 нче класстан.



Аннан семинарда катнашучылар һәм укучылар алдында язучы үзе чыгыш ясады. Ул үзенең тормыш юлы турында сөйләде, шигырьләрен укыды, балаларның сорауларына җаваплар бирде. Федор Афанасьевич шулай ук район мәктәпләрендә чуваш телен һәм әдәбиятын укытуны яхшырту белән бәйле мәсьәләләргә дә тукталды.

Фикер алышу барышында укытучылар мондый чараларның файдалы булуын билгеләп үттеләр, шундый очрашуларны ешрак оештырырга кирәк диделәр.

Кызганычка каршы, семинарда район мәктәпләрендә чуваш теле укытучыларының барысы да булмады. Ә бит мондый чаралар чуваш теле һәм әдәбиятын укытуда бердәм алымнар эшләү һәм безнең шартларда чуваш телен үстерү юлларын эзләү күзлегеннән бик мөһим.

**М.ПАРУКОВА.**

**Рәсемдә: Г.М.Ендиряков дәрестә.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

***Фома мәктәбе укучылары иҗаты***

***Каләм сынау***

# АВЫЛ КҮРКЕ - МӘКТӘБЕМ

Мәктәбебез авыл уртасына урнашкан. Аның җитәкчелеге максатчан һәм тырыш булганга, белем алу учагыбыз чиста, җылы. Быел ул табигый газ белән җылытыла. Ул эшкә укытучыларыбызның күп өлеше керде. Ир - ат укытучылар мәктәп янында газ мичен урнаштыру өчен корылма төзеп куйдылар.Ул "ак йорт" - укытучыларның ярдәмчел, киң күңелле, алтын куллы икәнлеген дәлилли торган корылма.

Мәктәп янында җыйнак кына бакча бар. Нәрсә генә үсми анда: яшелчәләрнең 7 - 8 төре, карлыган, алмачия кебек җиләк - җимешләр дә байтак булды. Болар һәммәсе дә - укытучыларыбыз һәм укучыларның хезмәт җимеше. Мәктәп ашханәсендә ел әйләнәсе түләүсез туклануыбызнәкъ шул уңыш нәтиҗәсе.

Көн саен озын тәнәфесне түземсезләнеп көтеп алабыз без, һәм бәхеткә ул бушка булмый: пешекчеләребез - Сәкинә һәм Гөлфия апалар безне һәрчак тәмле ашлар, салатлар белән сыйлыйлар.

Класс бүлмәләребез дә күркәм, укыйм дисәң, бөтен мөмкинлекләр дә бар. Шуңа күрә укуында яхшы нәтиҗәләргә ирешүчеләр дә күп. Үткән елда Римма Сәлахова мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, Казан дәүләт университетына укырга керде. Көмеш медальгә тәмамлаучылар саны уннан артты.

Мәктәптә ел саен классташлар очрашуын үткәрү традициягә әйләнде. Балачак хатирәләрен күңелендә саклаган укучылар бик күп җыела.

Мәктәбебез безгә ошый, шуңа да тырышып укыйсы гына кала.

**Г.МӨХӘММӘТШИНА,**
**X сыйныф укучысы.**

# «ИҢ КУЛАЙ АЧКЫЧ»

Укытучы. Бу сүзне әйтүгә минем күз алдыма мөлаем йөзле, йомшак карашлы беренче укытучым - Флүсә апа килеп баса. Ул безне - җиде бөртек сабыйны, кулларыннан тотып тәүге тапкыр белем дөньясына алып керде.

... Тактага тигез итеп "А" хәрефе язылган. "А" - әлифбаның башлангычы, беренче сыйныф ишеген ачу өчен "иң кулай ачкыч",- диде ул безгә. "Иң кулай ачкыч"? Без моны аңлап бетермибез. Ничек инде, кара тактага акбур белән сызылган хәреф ишек ачкычы була ала? Аның күчерелмә мәгънәдәге сүз ролен үтәвен без соңрак төшенәбез.

Һәр дәрес башында Флүсә апа бер үк сүзләрне кабатлый: "Кара тактага акбур белән язу - ул надан кешенең кара күңеленә алтын нур сызу". Тик бу сүзләрнең мәгънәсен без бүген дә аңлап бетермибездер әле, мөгаен. Ләкин алар беркайчан да күңелдән чыкмый.

Бу көннәрдә Флүсә апабызның туган көне. Бәйрәмең белән сине, укытучым! Уңышларыңа сөенеп, бәхет хисе кичереп яшә. Һәр таңны сау - сәламәт каршыла.

**А. МӨХӘММӘТШИНА,**
**VII сыйныф укучысы.**

# УҢЫШ БӘЙРӘМЕ

Күптән түгел безнең Фома мәктәбендә Уңыш бәйрәме булып үтте. Ел да ул бәйрәмне без түземсезлек белән көтеп алабыз. Чөнки ул көнне тәмле - тәмле ризыклар белән сыйланып кына калмыйбыз, күп төрле могҗизалар да күрәбез. Укытучылар яшелчәләрдәнниләр генә ясамыйлар! Быел да ташкабактан - көймәләр, вагоннары белән паровоз, төрле савыт - сабалар, бәрәңгедән - телефон, кабактан кешеләр, битлек - һәммәсе дә гаҗәпкә калдырды. Шуннан алган тәэсирләремне өйгә кайткач шигырь итеп яздым.

*Бүген бездә бәйрәм бит,*
*Җыйналыштык бергәләп.*
*Уңышны алып килдек*
*Һәрберебез бик күпләп.*
*Басып тора кешедәй,*
*Бар иде анда кабак,*
*Виноград, карбыз, кишер*
*Тутырылган бер табак.*
*Алка таккан кешене*
*Каравы бигрәк кызык.*
*Атлап китәр шикелле,*
*Күзләре аның кысык.*
*Күрдек хәтта ташбака -*
*Кабыгы таш диярсең.*
*Ип - исән бит, син кара,*
*Тотсаң һуштан китәрсең.*
*Бик күңелле булды шул*
*Бергәләп җыйналуы.*
*Рәхәтләнеп ял итеп,*
*Тәмле итеп сыйлануы.*

***Г. КАНӘФИНА.***
***VII сыйныф укучысы.***

# МУЗЫКАНТЛАР КИҢӘШТЕ

Күптән түгел генә шәһәр һәм район мәктәпкәчә балалар учреждениеләрендә эшләүче музыка хезмәткәрләре үзләренең методик берләшмәләренә киңәшмәгә җыелдылар. Бу көнге сөйләшү сәләтле балалар белән эшләүгә багышланган иде. Көн тәртибенә куелган мәсьәләләрне уртага салып сөйләшкәннән соң, һәммәсе дә яшь белгеч Л.В.Показаньеваның ("Камыр Батыр") экологик темага хәзерләнгән ачык дәресен карадылар. Бу музыкаль дәрестә балалар үзләренең табигать турында җырлар, шигырьләр, сынамышлар һәм табышмаклар гына түгел, күп кенә фәнни мәгълүматлар да белүләрен күрсәттеләр. Дәрестә рәсем сәнгатенә дә урын бирелгән иде. Семинарда катнашучылар дәресне уңай яктан билгеләп үттеләр, укытучының музыкальлегенә аеруча игътибар иткәнлекләрен әйттеләр. Методик берләшмәне күп еллар дәвамында җитәкләүче, тәҗрибәле һәм инициативалы белгеч В.Г.Чечнева да укытучының эшчәнлеген бәяләп, уңай сүзләр әйтте. Таләпчән һәм эшлекле остазның бу сүзләре яшь белгеч өчен олы юлга фатиха булып яңгырады.

**Р.ХӘСӘНШИНА,**
**методист.**

# ХАТЫН - КЫЗЛАР ВОЛЕЙБОЛ УЙНЫЙ

Шушы көннәрдә районда хатын - кызлар арасында волейбол буенча ярышлар башланды. Анда шәһәрнең икенче мәктәбеннән - ике, өченче мәктәп белән шикәр заводыннан - бер һәм дүртенче мәктәптән бер команда катнашалар.

Хатын - кызлар арасында волейбол ярышлары тәгәлләнүгә, бәйге ир - атлар арасында башланачак. Анда командалар ике тапкырга артыграк булачак.

**Ш.ТЮКАЕВ.**

## TV

**ПОНЕДЕЛЬНИК**

### 9 НОЯБРЯ

**ОРТ**

8.00 "На графских развалинах".
9.05 "Ералаш".
9.30 16.35 "Дисней-клуб".
10.00 15.00 18.00 00.15 Новости
10.15 Домашняя библиотека.
10.35 "Чердачок братьев Пилотов"
11.10 Каламбур.
11.40 Крестьянские ведомости.
12.10 "Все путешествия команды Кусто".
13.20 "Пропавшая экспедиция".
15.15 Смехопанорама.
15.50 Клуб путешественников.
17.30 Гибель Гагарина. Факты и версии.
18.15 "Золотая лихорадка".
18.50 "Женские истории".
19.20 "Укол зонтиком".
21.00 Время.
21.40 "Захват-2.Территория тьмы".
23.30 "Взгляд".
00.35 "Комиссар".

**РОССИЯ**

8.00 "Три ветерана".
9.30 Мультфильмы.
10.00 Доброе утро, Страна!
10.35 Концерт.
11.30 Подиум д'Арт.
11.55 "Домашние хлопоты с Н.Варлей".
12.25 Концерт.
14.00 20.00 Вести.
14.30 "Марьина роща".
15.00 50х50
16.10 "Закон и порядок".
17.00 Звезды XXI века.
18.00 Моя семья.
19.00 Сиреневый туман.
20.30 Аншлаг.
21.00 "Приятель покойника".
22.50 Любовь с первого взгляда.
23.15 "Дежурная часть".
23.40 Горячая десятка.

**РИО**

17.05 Телемагазин.
17.25 0.00 ДИСК-канал.
18.00 23.30 Дорожный патруль
18.20 "Волчья кровь".
20.00 "Новости дня".
20.30 "Я шпион снова".
22.20 "Красная полоса".
23.00 "Катастрофы и войны недели"
0.35 "Знак качества".
0.45 "Врата дракона"

**ВТОРНИК**

### 10 НОЯБРЯ

**ОРТ**

6.00 Доброе утро.
9.00 12.00 15.00 18.00 00.15 Новости
9.15 Поле чудес.
10.20 "Взгляд".
11.05 "Смехопанорама".
11.50 Домашняя библиотека.
12.15 "Вместе".
13.05 "Анискин и Фантомас".
14.30 Мультфильм.
15.15 "Новые приключения Синдбада".
15.45 Счастливый случай.
16.30 До 16 и старше
17.00 "Жестокий ангел".
18.15 Угадай мелодию.
18.45 Час пик.
19.00 Тема.
19.45 "Скарлетт".
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.50 "Сыщик".
00.30 Хоккей.

**РОССИЯ**

7.00 Доброе утро, Россия!
9.15 23.45 Дежурная часть.
9.35 "Программа передач".
9.55 "Товары - почтой".
10.00 "Санта-Барбара".
10.45 "Музыка, музыка..."
11.00 14.00 17.00 20.00 0.00 Вести.
14.35 "Династия-II: семья Колби".
15.20 "Богатые и знаменитые".
16.15 "Сказочный полдник".
16.30 Мультфильм.
20.35 Подробности.
20.40 Концерт.

**РИО**

17.05 0.35 ДИСК-канал.
17.35 23.55 Дорожный патруль.
18.00 0.10 ТСН-6.
18.25 "Грейс в огне IV".
18.55 "Защитница".
20.00 "Новости дня".
20.30 "Мужской клуб".
21.25 "Петроград. Июль 1917".
22.25 "Красная полоса".
23.25 "Назло рекордам"
0.20 Те Кто.
1.10 "Знак качества".

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Якты Күл авылында яшәүче **кадерле әниебез, Туган Әбиебез Гөлфизә Һади кызы Хисамованы** туган көне белән кайнар котлыйбыз.

Һәр яңа көн шатлык алып килсен,
Сәламәт бул калган гомердә,
Диеп бүген сиңа теләк тели
Балаларың туган көнеңдә.

**Фәнис, Бибинур, Фидаил, Алсу.**

Зирекле авылында яшәүче **кадерле әниебез Асия Сәйфелмөлек кызы Әхмәтҗановань** юбилее белән чын күңелебездән котлыйбыз, ныклы сәламәтлек, озын гомер, бәхет, гаилә һәм җан тынычлыгы телибез.

Туган көннең ямьле мизгелләре
Күңелеңдә калсын уелып.
Тәбриклибез сине чын күңелдән.
Барыбыз да бергә җыелып.

**Улың, кызларың, кияүләрең һәм оныкларың.**

Нурлат шәһәрендә яшәүче **кадерле әтиебез Минһади Мәхмүт улы Нигъмәтуллинны** 70 яше белән кайнар котлыйбыз.

Син булганда без дә бәхетлебез,
Бөтен яме синдә дөньяның.
70 яшең белән котлап сине
Бәхет тели улың, кызларың.

**Тормыш иптәшең, балаларың, оныкларың.**

Якты Күл авылында яшәүче **кадерле әти - әниебез Хөсния Һади кызы һәм Җәмил Мирзаһит улы Бикиевларның** бергә гомер итүләренә 40 ел тула. Авырмыйча озак еллар тигез яшәүләрен телибез.



**Барлык балалары исеменнән кызлары Гөлфия.**

Киекле авылында яшәүче **кадерле әниебез Роза Фәтхетдин кызы Җамалетдинованы** 60 яшьлек юбилее белән котлыйбыз.

Әни бит ул өйнең яме,
Ә тормышта олы бер терәк.
Озак яшә, сәламәт бул,
Син бит, әни, безгә бик кирәк.

**Изге теләкләр белән балаларың исеменнән кызың Рәмзия.**

**Криминаль тарих**

# КҮПЕР ТӨБЕНДӘ ҮТЕРҮ

## Яки пенсия акчаңны кая тотканыңны белмәсәң...

31 октябрьдә иртән Мамык авылында, Вишневая Поляна урманчылыгының элеккеге контора бинасы янында күкрәге, корсагы һәм муенында күпсанлы кадалган - киселгән урыннар булган ир -ат мәете табыла. 32 яшьлек II группа инвалид Виталий Марфуткин булып чыга ул. Авылга оператив тикшерү төркеме юнәлә. Сәгать кичке дүртләргә җинаять кайнар көенә ачыла.

... Бөтенесе дә элекке көнне кичтән А. йортында җыелышып утырудан башлана. Чәркә артыннан чәркә, сүз артыннан сүз китеп, шактый кызып җиткән йорт хуҗасы кунакка үзенең күптәнге үпкәләрен исенә төшерә һәм кулына авыр кисәү агачы ала. Марфуткин өстендә булган киемнән генә ишеккә ташлана, әмма А.аны 100 метр арада ук куып тота һәм күп тапкырлар пычак белән кадый. Тегесе шунда ук үлә. А. тиз генә өенә кайта да, эзләрне бетерергә керешә: пычагын, үзе үтергән кешенең итеген һәм телогрейкасын яшереп куя. Үзе дә базга төшеп утыра, әмма, озакка түгел икән шул - эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләре шуннан табып алалар аны.

P.S. Моңа охшаш җинаятьләр безнең тормышыбызда аз түгел хәзер. Эчү мәҗлесе күп очракта "исәнлеккә" дип башланып кына китә шул ул, әмма ахыры еш кына әнә шулай үкенечле бетә. Ә болар эчәргә акчаны каян алганнар соң? Баксаң, А.ның әти - әнисе күптән көткән пенсияләрен алганнар икән. Мондый вакыйганы ничек "юмыйсың" ди инде?

Шушы криминаль вакыйга уңаеннан, редакциягә берәүнең шалтыратканы хәтергә килде. Бер пенсионер азык - төлек карточкасына аракы бирмәүләреннән, һәм шул сәбәпле улын адәм рәтле каршы ала алмавыннан, ә аракысыз бәйрәмнең ни кызыгы бар инде дип зарланды. Ә менә мондый "бәйрәм"нең ни кызыгы бар икән соң?

**Т.АЛЕКСЕЕВА.**




С.Майстер фотосы.

# ИГЕЛЕК БЕЛӘН ИЗГЕЛЕК БЕРГӘ ЙӨРИ

Күптән түгел Серафим Саровский һәм Илья пәйгамбәр чиркәүләренә Казан епархиясеннән Дини семинариягә яшелчә, җиләк - җимеш яки азык - төлек җибәрү мөмкинлеге табарга дип әмер килеп төште. Әмердә дини мәктәпнең ихтыяҗларына ике приход прихожаннары да битараф калмаслар дигән ышаныч та белдерелгән иде. Һәм без шул бурычны үтәү ниятеннән район авылларына чыгып киттек.

Андреевкада без 70 яшьлек Нина Петровна Будяшкина белән очраштык. Үзе ул Чувашиядән, 48 нче елда Казанда институт бетергән дә, пенсиягә чыкканчыга кадәр шушы мәктәптә математика укыткан. Авылда күптән үз кешегә әверелгән инде ул, ире белән биш бала үстергәннәр, хәзер ун оныклары бар. Нина Петровна - дингә ышана, ә андыйлар гадәттә намуслы, эш сөючән булалар һәм әхлак кануннарын олылыйлар. Н.П.Будяшкина безне авыл кешеләре белән очраштырды һәм алар бик киң күңелле булып чыктылар, дини семинариягә хәлләреннән килгәнчә булыштылар.

Ике приход хуҗалары исеменнән дә без шулай игелекле һәм игътибарлы булулары өчен Андреевка авылы халкына рәхмәт белдерәбез. Иминлек һәм рух шатлыгы телибез Сезгә.

**Чиркәү советлары. Нурлат шәһәре.**

***"Нурлат сәүдә базасы" АҖ туңдырылган свежий балык сата.***

***Ассортиментта:***
***Треска - 15 сум 70 тиен;***
***- Навага - 11 сум 50 тиен;***
***- Камбала - 11 сум 50 тиен;***
***- Мойва - 7 сум 80 тиен.***
***Түмәрләп алганда - ташлама ясала.***

### САТАБЫЗ ЯКИ АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Ике гаиләлек коттеджадагы өч бүлмәле фатирны (гомуми мәйданы 82 кв. м, 6 сутый бакчасы, мунчасы бар) - өстәмә түләп ике бүлмәле фатирга.** Адрес: Космонавтлар ур., 33 - 2.

### АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Свердловск өлкәсенең Югары Тагил шәһәрендәге (Екатеринбургтан 65 км.да) уңайлыклары булган һәм телефонлы ике бүлмәле фатирны - Нурлатта, Кошкида шуңа тиңгә, вариантлар мөмкин.**

Нурлатта 2-21-15 (эш) телефоны буенча һәр көнне иртәнге 8дән кичке 5кә кадәр мөрәҗәгать итәргә.

### КЕМЛЕГЕН АЧЫКЛАРГА БУЛЫШЫГЫЗ

***Нурлат эчке эшләр бүлеге Нурлат разведка бораулавы идарәсе территориясендә үз үлеме белән үлгәнгә охшаган ир -ат мәете табылуын хәбәр итә. Аерым билгеләре: яше 40-50ләрдә, буе 167 см., ябык гәүдәле, чал төшкән кара коңгырт кыска чәчле. Өстендә кулдан бәйләнгән сирень төсендәге пуловер, аклы - аллы шакмаклы киҗе-мамык күлмәк, соры төстәге киҗе - мамык чалбар, аякларында кара төстәге кыска кунычлы резин итекләр. Сул кулының чугында хәрефле наколка бар.***

2-12-32, 2-19-02, 02 телефоннары буенча шалтыратырга.

## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА.

### САТАБЫЗ

**Ключи поселогында йорт.**
Мәскәү ур., 5-36 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.

***

**1988нче елгы ВАЗ-2108.** Адрес: 60 лет Октября ур., 21-10 (азык-төлек базары янында), кичке 6дан соң.

***

**1991нче елның декабрендә чыккан, кара төстәге ВАЗ-21043 (бик әйбәт хәлдә).** Тел.: 3-52-46.

***

**4нче мәктәп ягында гараж.**
Адрес: Совет ур., 195 - 36.

***

**Ике бүлмәле фатир.** Тел.: 2-10-20.

***

**"Альянс" (универмаг), "Елена" (кием - салым базары) кибетләре "Стинол", "Норд","Орск", "Юрюзань" суыткычлары саталар. Гарантия бар, өстәмә түләүсез илтеп бирелә.**
**Кибет сатыла (азык - төлек базары).** Тел.: 5-41-19.

***

***"Абсолют" кибете капчыгын 110 сумнан югары сортлы он, 370 сумнан шикәр комы сата. Өстәмә түләүсез илтеп бирелә. 3,5 мм.лы кара металл.***
В - 98 сер. 022366 номерлы лицензия.

***Кадерлебез Рәшид Гали улы Кәримовның*** вафат булуына 8 ноябрьдә 2 ел тула. Туганнарның, дусларның, хезмәттәшләренең Рәшидне искә алуларын телибез.

**Хатыны Гөлнур, балалары.**

***Газетабызның киләсе саны 11нче ноябрьдә чыга.***


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. 4264